# КАРАР

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл жирлеге составына керүче Иске Пәлчекәү торак пунктында гражданнар жыены нәтижәләре турында**

**11.11.2024** **№ 2**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законынын 35 статьясы нигезендә 2024елның 11 нче ноябрендә булып узган гражданнар жыены нәтижәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:« Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл жирлегенең Иске Пәлчекәү торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2025 елда үзара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертүгә һәм жыелган акчаларны жирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга
- авыл территориясен төзекләндерү.

Гражданнар жыены нәтижәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган жыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар жыенында катнашучы 35 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 28 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтижәләре буенча халык жыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 28 жыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 0 жыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык жыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл жирлегенең Иске Пәлчекәү торак пунктында гражданнар жыенын узган дип танырга, халык жыены нәтижәләрен дөрес дип санарга.

2. Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл жирлегенең Иске Пәлчекәү торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2025 елда

үзара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:
- авыл территориясен төзекләндерү- соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында кабул ителгән көннән.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгы Камалиева Л.М.